**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

---

**2022 елның 1 апреле** **27 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 февралендәге 96-РС номерлы үзгәрешләр белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 61-РС номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, кешенең тормыш эшчәнлегенең уңай шартларына хокукын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Лаеш шәһәре Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә;

2. Кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар уздыру чорын - гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итү мизгеленнән башлап нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы кимендә бер айдан ким һәм өч айдан артык була алмый;

3. 3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган иҗтимагый фикер алышуларның башлануы турында хәбәр итәргә;

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 14 эш көне дәвамында әлеге Карарның 3.1 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы билгеләгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.3. Әлеге Карарның 2 п. күрсәтелгән чорда гавами тыңлаулар уздырырга;

3.4.Гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне ахыргы карарны кабул итү өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә..

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

. 6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лаеш шәһәренең Җирдән файдалану, төзелеш, төзекләндерү һәм экологик куркынычсызлык мәсьәләләре буенча комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - Лаеш муниципаль районы**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**